Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№29 (122)

16 октябрь 2014 ел



Фундаменталь медицина һәм биология институтының «Молекуляр фармаколог» белгечлеге буенча 5 курста белем алучы Адинаның барлык казанышларын һәм башкарган эшләрен язып бетерү өчен тулы газета да җитмәс иде. Ул 4 тапкыр РФ Хөкүмәте стипендиаты да, «Ел студенты» премиясе җиңүчесе дә, «Универсиада уты эстафетасы» проектын оештыручы да, «Созвездие-Йолдызлык» фестивале җиңүчесе дә, КФУның «Студентлар язы» фестивале призеры да һ.б. бик күп исемнәр иясе дә. Шулай ук сез аның исемен Россия рекордлар китабында күрә аласыз!

# «Командама тулысынча ышанам!»

**Таныш бул!**

# «Командама тулысынча ышанам!»

Алинә САДЫЙКОВА

Сәхифәбезнең бүгенге кунагы – мөлаем, нәфис һәм нечкә күңелле кыз Адина Кульмасова! Ул университетыбызның иң актив, иң талантлы студентларының берсе.

**– Адина, үзең белән таныштырып кит әле.**

- Тумышым белән мин Казахстан республикасының нәкъ үзәгендә урнашкан данлы Караганда шәһәреннән. Милләтем буенча яртылаш - татар, яртылаш - башкорт. Шуңа күрә һәрвакыт тарихи туган илемә тартылдым. Миңа 15 яшь тулгач, гаиләбез белән Татарстанга, Чистай шәһәренә күченеп килдек. Анда мин мәктәптә 3 ел укыдым һәм үз-үземне табу өчен Казанга килдем. Казан - дөньядагы иң яраткан шәһәрем! Чит илләрне күп күрдем: Европаны да, Азияне дә. Шулай да минем өчен иң җылы, иң якын, иң якты шәһәр - ул Казаным!

**- Казанда бик актив иҗтимагый тормыш рәвеше алып барасың. Әлеге эшчәнлеккә ничек килеп кердең? Беренче адымнарың нинди иде?**

- Әйе, чыннан да, Казанга килү белән, бик кызыклы студент тормышым башланып китте. Бөтен кешеләр кебек үк, мин дә актив студент, волонтер булдым. Барлык акция, волонтерлык хәрәкәтләрендә, чараларда катнашырга тырыштым. Билгеле булганча, бездә ТРның Студентлар Лигасы, иҗади эшләр академиясе, яшьләр эшләре буенча комитет бар. 5 ел дәвамында әлеге оешмалар эшчәнлегендә кайнадым һәм хәзер мин - Студентлар Лигасының совет әгъзасы, «Российский союз молодежи» республика яшьләр иҗтимагый оешмасының идарә әгъзасы, Казан шәһәре башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр комитетының яшьләр белән эшләү буеча белгеч һәм, ниһаять, Универсиада авылының Студентлар ассоциациясе рәисе. Менә хәзер, 5 ел югарылыгыннан караганда, динамик үсешемне күрәм. Гомумән, лидерлыкны мин велосипедта йөрү белән чагыштырам. Син я алга барасың, я егыласың. Бүтән вариантлар юк. Менә шундый девиз астында инде 5 ел буе уңышларга ирешәм.

**- Уңышка ирешү өчен нинди сыйфатларга ия булырга кирәк?**

- Мин бик җаваплы кеше. Эшне һәрвакыт вакытында эшләп барам. Бу сыйфатны миндә кечкенәдән үк әти-әнием тәрбияләде. Әле дә хәтерлим: мәктәптә беренче сменада укыганда, әнием һәрвакыт: «Кызым, китап-дәфтәрләреңне кичтән үк әзерләп, портфелеңә тыгып куй. Иртә беләнгә калдырма», – дип әйтә иде. Шулай эшли идем һәм һәрвакыт бөтен әйберем тәртиптә була иде. Әйберләрем дә тәртиптә, эш урыным да тәртиптә. Нәкъ менә шуннан фикерләүдә дә тәртип барлыкка килә. Менә шушы сыйфатлар үземне, эшемне дөрес оештырырга һәм уңышка ирешергә ярдәм итә.

**- Синең эшчәнлегең бик күпкырлы. Барысына да вакытны ничек җиткерәсең?**

- Күңелемә якын булган әйбер белән шөгыльләнәм һәм эштәге приоритетларны аерып куям. Үз командам бар. Аңа тулысы белән ышанам, без бер-беребезгә һәрвакыт ярдәм итеп торабыз. Ә башкача булмый да бит! Бер генә тапкыр яшибез һәм, мөмкинлек булганда, бөтен нәрсәне дә татып карарга кирәк.

**- Ә уку белән мөнәсәбәтләрең ничегрәк?**

- Әгәр кеше табигате белән лидер икән, ул - барлык өлкәләрдә дә лидер. Шул исәптән, фән дөньясында да. Укуга килгәндә, мин аны бик яратам. Һәрдаим төрле конференцияләр, фәнни чараларда катнашам. Танылган чит ил журналларында фәнни мәкаләләрем дә басыла. Бу юнәлешне сайлаганда ялгышмаганлыгыма көн саен инанам. Мин әле институт эчендәге биохимия кафедрасының молекуляр-генетик анализ лабораториясендә эшлим. Миңа бу өлкә бик тә кызыклы. Безнең институтта барлык кирәкле җиһаз, реагент һәм реактивлар да бар. Шуңа күрә эшлисе генә килеп тора.



*Адина – гарәп телендә «изге җомга, бәйрәм» дигәнне аңлата. Дусларым гел: «исемең дә, фамилияң дә үзенчәлекле», – дип шаяралар. Мин мәктәптә укыган вакытта ук, культмасса секторы рәисе идем. Шуңа күрә мине Кульмасова – Культмассова дип йөртәләр иде.*

**- Адина, күренеп тора: син - максатларыңа ирешә торган кыз. Ә балачакта хыялың бар идеме? Һәм син аны тормышка ашырдыңмы?**

- Кечкенә чагымдагы иң беренче хыялым - укытучы булу иде. Хәзер инде ул андый зур хыял түгел. Шулай ук сәяхәт итәсем килә иде. Кечерәк булганда, стенада эленеп торган картаны һәм атласны карап утырырга ярата идем. Шуңа күрә хәзер дә географияне бик яхшы беләм. Бик тә сәяхәт итәргә яратам һәм булып киткән җирләремне картада билгеләп барам. Узган ел Россияне буеннан-буена айкап чыктым. Универсиаданың ут эстафетасы миңа шундый мөмкинлек бирде: Владивостоктан алып Калининград, Архангельскидан Сочига кадәр сәяхәт иттек. Менә шундый марафон вакытында Россиянең күп кенә эре шәһәрләрендә булдым. Күптән түгел генә тагын бер бәхет елмаеп куйды әле. Прагада уздырылган Халыкара мәгариф мәктәбендә катнаштым. Аны ТРның Студентлар лигасы оештырды. Шунда белем бирү программасын да үзләштердем, шул рәвешле сәяхәт белән укуны берләштердем. Шулай итеп, әкренләп, хыялымны тормышка ашыра барам. Барысы да үз кулларыбызда!

**- Үзеңне бер биш елдан соң ничек итеп күз алдына китерәсең?**

- Минем яраткан тормыш иптәше, бәхетле ана, әлбәттә, өйдә утыра торган итеп түгел инде (*көлә – А.С.*), яшьләр сәясәте өлкәсендәге проектларны уңышлы тормышка ашыручы леди буласым килә. Минем өчен гаилә беренче урында тора. Көн саен Аллаһы Тәгаләгә әтием, әнием һәм энем өчен, аларның исән-сау булганнары өчен рәхмәт әйтәм.

*P.S. Шундый якты һәм гел елмаеп торучы кешеләр белән аралашканнан соң, үзеңне тагын да бәхетле һәм җиңел итеп тоя башлыйсың. Адинага һәр эшендә шундый ук җиңеллек һәм уңышлар телибез!*

**Хәйрия эше**

15-17 октябрь көннәрендә Универсиада авылында «Мин Универсиада авылы доноры» дип аталган акция уза. Авыру һәм канга мохтаҗ кешеләр язмышы өчен битараф булмаган КФУ студентлары бу чарада актив катнаша.

# Син дә безгә кушыл!

Илмир ВӘЛИЕВ,
Математика һәм механика институты

Акция Юридик факультетның социаль комитеты, КФУның Валеология үзәге һәм Универсиада авылының беренче (3 подъезд) һәм уникенче өйләренең активистлары ярдәме белән оештырыла.

Акция һәм аның максатлары турында Юридик факультетның социаль оештыручысы А.Юнусов болай диде: «Мондый акцияләрне беренче уздыруыбыз түгел, чөнки, билгеле, университетыбызда хәйрия эше бик актив алып барыла. Минемчә, бу акцияне оештырып, без бик зур эш башкарабыз, чөнки студентлар тарафыннан авыру, канга мохтаҗ кешеләргә ярдәм күрсәтелә һәм шул ук вакытта изге эш тә башкарыла. Акциянең максатлары булып, донорлык хәрәкәтенең үсеше һәм университетта бердәм донорлар базасын оештыру, формалаштыру тора. Кан бирергә теләүче студентларны без өч көн дәвамында Универсиада авылының 15нче өендә, 9.00-15.00 сәгатькә кадәр көтеп калабыз».



Донор сүзе латинчадан «бүләк» дигәнне аңлата. Чыннан да, донорлар үзләренең туганнары, якыннары өчен генә түгел, ә бер дә таныш булмаган кешенең тормышы өчен дә изге эш башкаралар. Кан бирергә риза булган студентлар тирә-юньдәгеләрдә, һичшиксез, хөрмәт хисе уята. Акциядә катнашучы Экология һәм табигый байлыклардан файдалану институты студенты Светлана шундыйларның берсе. «Әгәр сәламәтлегең әйбәт икән, ни өчен барып кан бирмәскә? Авыру кешеләргә ничек тә булса ярдәм итә алганыма мин чиксез шат. Процедурадан соң бераз башым әйләнә, ләкин үземне әйбәт хис итәм», – ди ул.

Кан бирергә теләүченең пропискада торуы һәм балигъ булуы мөһим. Шулай ук аның авырлыгы 50 килограммнан да ким булмаска тиеш. Кан бирүчеләргә 300дән 600 сумга кадәр акча түләү һәм ике көн ял каралган.

Акция 17 октябрьгә кадәр дәвам итәчәк.

**Бездә кунак бар**



# Хезмәттәшлеккә бер адым

13 октябрьдә уку йортыбызга «Нефть-газ бассейннары стратиграфиясе» OpenLab җитәкчесе, Фрайберг тау академиясе профессоры Йорг Шнайдер килде.

Визиты кысаларында ул Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты җитәкчелеге белән очрашты. Фрайберг тау академиясе дөньядагы иң борынгы тау уку йортларының берсе булып санала. Аңа 1765 елда ук нигез салынган. Академиядә барлыгы 5 факультет бар: математика, табигать фәннәре, тау эше, металлургия һәм инженер-икътисади. Уку йорты механика, геология, тау эше, металлургия, химия, электротехника, физика, энерготехника, геодезия өлкәләрендә эшләүче белгечләр әзерләп чыгара.

КФУда узган эшлекле сөйләшүдә сүз «Нефть-газ бассейннары стратиграфиясе» фәнни-тикшеренү лабораториясенең фәнни һәм гамәли эшчәнлегенең нәтиҗәләре, үсеше турында барды. Шулай ук ике уку йорты арасында икеләтә диплом проектын булдыру мәсьәләсе күтәрелде. Йорг Шнайдер визитының төп максаты уку йортыбызда 21 октябрьдә узачак Н.А.Головкинский ис. фәнни-гамәли стратиграфия конференциясе белән бәйле.

• Тарих сәхифәләре

Биттәге язмаларны **Ләйсән ИСХАКОВА** әзерләде, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

# Казан университеты тарихында – Акчуриннар

Акчуриннар – татар дөньясында киң танылган, халкыбызның йөз аклыгына әверелгән нәсел. Хәйриячелек белән шөгыльләнгән, милләт тормышында якты эз калдырган әлеге нәселнең бер вәкиле – Мәрьям Әлим кызы Акчурина узган гасырның 20нче еллары уртасында Казан университетының медицина факультетында укыган.

Бирелә уку бәхете, әлбәттә, һәркемгә тәтемәгән. Ул заманда да Казан университетында белем алу зур дәрәҗә саналган. Бигрәк тә татар хатын-кызлары өчен. Архив материалларына күз салсак, хәтта революциядән соң да университетта белем алучылар арасында татарлар артык күп булмаган. Булганнарының күпчелеге исә уку йортына ирекле тыңлаучы буларак йөргән.

КФУның Н.И.Лобачевский исемендәге китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар булегендә Мәрьям Акчуринаның документлары бүген дә саклана.

Сүз уңаеннан, моннан 200 ел элек, 1814 елда Казан Император университетында медицина факультеты ачыла. 1830 елда аның базасында Казан дәүләт медицина университеты оеша.

Университетны тәмамлаганнан соң, Мәрьям Акчурина Казандагы Табибларны камилләштерү институтының балалар клиникасында педиатр булып эшли. Соңрак ул татар язучысы, әдәбият галиме Гомәр Толымбайскийга кияүгә чыга. Белгәнебезчә, язучы хаксыз рәвештә сәяси репрессиягә эләгә. 1938 елның 14 маенда, «халык дошманы» хатыны булуын сәбәп итеп, Мәрьям Акчуринаны да кулга алалар. Күренекле сәүдәгәрләр һәм фабрикантлар нәселе вәкиле 8 елга лагерьга сөрелә. НКВДның Нократ төзәтү-хезмәт лагеренда да ул, Гиппократ антына тугры калып, үзен аямыйча табиб булып эшли. Моның шулай икәнлеген пациентлар гына түгел, житәкчеләр дә билгеләп үткән. Үз эшен һәрчак намус белән башкарганы өчен, Мәрьям Акчуринаның төрмә срогы 3 елга кыскартыла. «Хрущев җепшеклеге» чорында ул тулысынча аклана.

*Материал Рәйсә Шәрәфиева ярдәме белән әзерләнде*




Мәрьям Акчуринаның предмет кенәгәсе. Безнеңчә, зачетка була. Әмма хәзерге заманныкыннан аермалы буларак, аның фотосы да аклы-каралы, пичәте дә сургучлы.




Мәрьям Акчуринаның студент билеты. Ул заманнарда аны «предъявитель» дип атаганнар. Университетка кергән вакытта нәкъ менә шушы рәсми кәгазьне күрсәткәннәр.




Университетны тәмамлаганнан соң, студентларга менә мондый таныклык бирелгән. Безнеңчә, югары белем алу турындагы диплом. Мәрьям Акчуринага 1927 елда тапшырылган әлеге таныклыкта аңа табиб квалификациясе бирелүе турында язылган.

• Алар бездә укыган



Тормышта һәрберебезнең истәлек итеп саклый торган әйберләре бардыр. Яшь дизайнер Миләүшә Сөләйманова өчен исә дәү әнисеннән калган чулпылар, хәситә, муенса-беләзекләр, татар милли бизәкләре чигелгән сөлгеләр – әнә шундый кадерле ядкәр.

# «Милли киемне брендка әверелдерергә кирәк!»

«Кызны кечкенәдән үк сандыктагы шул борынгы җәүһәрләрнең зәвыклылыгы, затлылыгы, бизәкләрнең матурлыгы сокландырган. Яшел Үзәннән булса да, балачагы Чүпрәле һәм Кама Тамагы районнарындагы авылларда узганга, үзен һәрвакыт авыл кызы дип атаучы Миләүшә бүген үзе дә татар милли киемнәре тегә, калфактүбәтәйләр чигә. Ул КФУдагы Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Сынлы сәнгать һәм дизайн кафедрасын әле узган ел гына тәмамлады. Шулай да үз эшен башлап җибәрергә курыкмаган – хәзерге көндә Миләүшә ателье ачу эшләре белән янып йөри.

Бүген хатын-кызлар өчен мөселман киемнәре тегү белән шөгыльләнүче дизайнерлар уңышлы эшләп килә. Бу соңгы елларга хас матур бер тенденция, дисәк тә, ялгышмабыз. Тик, ни кызганыч, аларның күбесе татар халкының милли үзенчәлекләрен исәпкә алмый. Татар хатыны элек-электән милли кием кигән. Ислам кануннары буенча яшәсә дә, ул гарәп хатын-кызлары кебек баштанаяк урнамаган. Калфак киеп, маңгай чачен капласа, яулык яки шәл салып, озын чәчен япкан, күлмәге һәм камзулы исә зифа буй-сынын ышерергә ирек биргән. Миләүшә, моны истә тотып, борынгы татар милли бизәкләре белән чигелгән, шул ук вакытта заманча стильдәге зәвыклы костюмнар тегә. Ул иҗат иткән үрнәкләр арасында никах күлмәкләре дә, сәйлән белән чигелгән нәфис түбәтәйләр дә, милли элементлар кулланып тегелгән көндәлек кием дә бар.

«Һәр халык үзенә генә хас рухи байлыгы, милли гореф-гадәтләре белән үзенчәлекле. Бу диндә дә ассызыклана. Дагстан, үзбәк, чечен халыкларыда мөселман, тик алар милли киемнәреннән баш тартмый. Бу халыклар үзләренең тарихын белә һәм аның белән горурлана. Бездә исә хәл башкачарак.

*Борынгыдан ук кием кешенең тышкы кыяфәтенә милли төс биргән. Киемнә карап, аның кайсы халык вәкиле икәнен белергә мөмкин булган. Бүгенге глобальләшү шартларында хәлләр башкача булса да, милли киемнәрдә халыкның гасырлар буена тупланган акылы да, тәҗрибәсе дә, тарихы да чагылуын онытырга ярамый.*

Татарлар үзләренең татар булуы белән горурланмый, тарихын белми. Югыйсә, борынгы бабаларыбыз заманында бөек дәүләтләр тоткан кавем... Әйе, бүген урамга милли стильдәге кием киеп чыксак, безне сәер дип атаячаклар. Әмма күпләр көн саен шулай киенеп йөри башласа, бу гадәти хәлгә әвереләчәк», – ди Миләүшә.

Бүген милли кием буенча һөнәри белгечләр бик аз икән. Хәзерге көндә тегелгән милли костюмнар еш кына бизәкләре белән дә, чигелеш-тегелешләре белән дә тарихи үрнәккә тулысынча туры килми, ди яшь дизайнер. Чөнки бу юнәлештәге махсус белгечләрне әзерли торган уку йорты юк. Үзе исә, костюм үрнәкләрен эшләгәндә, элеккеге чорга хас элементларны, бизәкләрне музейларга йөреп, иске фотолардан карап узләштергән.

Милли киемнәрне, нигездә, никах өчен сорасалар да, халык орнаментлары төшерелгән күлмәкне көндәлектә киеп йөрү өчен алучылар да юк түгел икән. Миләүшә, милли киемне брендка әверелдерү кирәк, дигән фикер житкерде. Үрнәк итеп, ул Италиянең күренекле Dolce&Gabbana брендының соңгы туплланма-коллекцияләрен китерде. Баксаң, әлеге компания дизайнерлары милли мотивларны кулланып тегәләр икән. Һәм бу киемне Италиядә генә түгел, бөтен дөньяда танып, яратып кияләр. Бүген милли мотивлар – модада.



«Милли стильдәге костюмнарга ихтыяҗ бар, тик фабрика ачарлык дәрәҗәдә түгел шул әле. Чөнки бәяләр гадәтидән югарырак. Күпләп житештерә торган предприятие ачуны нинди дә булса кечерәк эштән башларга кирәк. Мин ательены сайладым. Аның ярдәмендә акча җыеп, милли киемнәр тегә торган фабрика ачу – киләчәк хыялым», – ди Миләүшә.

***P.S.** Миләүшә хатын-кызларның борынгы милли бизәнү әйберләренә дә заказлар кабул итә. Дизайнер бу юнәлештә эшләүче зәркәнчы таппкан. Әлеге оста борынгы үрнәкләр нигезендә кыйммәтле асылташлардан ювелир эшләнмәләр ясый.*

• Әдәби сәйләннәр

# Рәнҗеш



Сәхифәбезнең бүгенге кунагы – яшь иҗатчы Зөһрә Вилданова. Кукмара районы Салтык-Ерыклы авылында дөньяга килгән кыз хәзерге вакытта Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегенең 1 курсында белем ала. Кечкенәдән үк әдәби китаплар укырга ярата. Илһам килгәндә, шигырьләр, хикәяләр яза. Кешеләрдә һәм, гомумән, тормышта гадилекне һәм гаделлекне ярата. Бүген без сезгә аның иң матур хикәяләренең берсен тәкъдим итәбез.

Көзге моңсу көн. Зур-зур караңгы болытлардан чиләкләп яңгыр коя. Авылга илтә торган юлдан челтер-челтер гөрләвекләр ага. Эре яңгыр тамчылары, кипкән агач яфракларын шыбырдата-шыбырдата, җиргә тамалар. Ул салкын җил, көчле яңгыр, кипкән сары яфраклар ниндидер серле һәм моңсу манзара тудыра. Тирә-якта бушлык, бер җан иясе дә юк кебек.

Мондый көннәрдә юлга чыккан кешеләр бик аздыр ул. Чү, юл кырыенда ниндидер җан иясе тора түгелме? Авылга илтүче сукмакта кечкенә песи баласы икән ул. Үзе ябык, йоннары юешләнеп беткән, бертуктаусыз мияулый, дерелди. Тамагы да ачтыр әле. Мескен песи баласы тәмам хәлсезләнгән, үлем хәленә җиткән. Кинәт юлдагы күлдәвекләрне чәчрәтеп, бер яхшы машинаның шул якка таба килгәне күренде. Әлеге чит ил маркалы яхшы машинада бер ир-ат белән хатын-кыз утыра иде. Күренеп тора: бик байлар. Өсләрендә яхшы кием, алтыннан бизәнү әйберләре. Алар – бертуган Газиевлар.

...Илдар белән Миләүшә Газиевларның берсе дә гаилә кормаган әле. Балачакларын бергә үткәрделәр, бергә укырга керделәр, бергә эшлиләр дә. Әтиләре бик кырыс, үткен акча сугучы иде. Балаларын да уңышлы гына эшмәкәрлек итәргә өйрәтте. Миләүшә белән Илдар әтиләрен иң бөек кешегә санап, аннан гел үрнәк алалар иде. Газиевларның төп девизы – барысын да үзләренә буйсындыру, акча белән барлык каршылыкларны да хәл итү. Нинди генә начарлыкка бармады инде Газиевлар акча өчен! Менә бу авылда аларга ни калган? Бу юлга Газиевлар ялгыш кына эләктеләр. Ялгыш кына микән, ә бәлки, язмыштыр да... Яңгыр алдыннан чыккан томан аркасында алар юлны бутадылар һәм кисәк кенә нәкъ менә шушы мескен песи баласы утырган юлга килеп чыктылар.

...Машина һаман песи баласына якынлаша бара, ә көчле яңгыр аркасында ул күренми. Соңгы мизгелдә генә Миләүшә «Тукта!» – дип кычкырып җибәрде. Ниһаять, алар да песи баласын күрделәр. Илдар, ачу белән тиз-тиз атлап, машинадан чыкты. Песи баласы ялварулы күзләре белән аңа төбәлде. Ачулы Илдар әллә бу күзләрне күрмәде, әллә аңа барыбер иде: ул мескен хайванны кулына алды да юл кырыена атты. Әйтерсең, песи баласы җан иясе түгел, ә чүп-чар...

Газиевлар берни булмагандай, машинага утырып, юлларын дәвам иттеләр. Илдарның Миләүшәгә: «Ник тиктомалга кычкырасың син? Шул песи баласын юлдан алам дип, яңгырда чыланып беттем бит!» – дип кычкырганы гына кайтаваз булып ишетелеп калды. Акчасы күп булган кеше күңелендә кечкенә генә песи баласына да урын табылмый икән шул.

Кинәт нәкъ шул юлда иске киемле, таякка таянган бер карт күренде. Авыл юлларын күзәтеп йөрергә яраткан Хәсән карт, яңгыр явуына карамастан, бүген дә юлында булды. Хәер, аның сәерлекләренә авылда игътибар итүче юк инде хәзер...

...Хәсән карт бөтен гомерен авыл халкына багышлады. Дөрес, ул бригадир, председатель дәрәҗәсенә ирешмәде, тик



һәр эшне җиренә җиткереп башкарды, халык хөр һәм бернинди җитешсезлексез яшәсен өчен бар көчен дә бирде. Намазын калдырмады, уразасын тотты. Революция еллары картның бик күп планнарын чәлпәрәмә китерде. Дәһшәтле революция авылны да эзсез калдырмады. Чират мәчеткә дә җитте, аның манарасын кисәргә килделәр. Халыкның күпчелеге моңа риза түгел иде, тик беркем дә каршылык күрсәтергә базмады. Ә Хәсән карт теше-тырнагы белән белән бу хәлне булдырмаска тырышты. Тик юкка гына бердәмлектә көч димәгәннәр шул: мәчет манарасы әкрен генә җиргә авып төште. Бу куркыныч мизгелләрне мәңге онытмас Хәсән карт. Ул халык белән, җитәкчеләр белән сөйләшеп, мәчетне кире үз хәленә кайтарырга теләде. Халык, күңеле белән хата ясавын сизсә дә, курыкты. Ә Хәсән карт бу хәлгә түзә алмады, халыктан читләште. Үзеннән-үзе килеп чыкты бу читләшү. Аннары инде сугыш башланды. Анда аның аягы яраланды. Күпме еллар Хәсән карт ялгызы яшәде, хатыны да, балалары да булмады. Авыл читендә яшәп ятучы карт хәзер беркемгә дә кирәкми инде.

Юлдан әкрен генә барганда, Хәсән картның күзенә теге кечкенә генә песи баласы күренде. Ул инде бөтенләй бетерешкән, хәлсезләнгән иде. Хәсән карт, аны күреп алгач, авырткан аяклары белән тиз-тиз атларга кереште. Өметне бөтенләй үк югалткан җан иясе, карт кулына алгач, ничектер уянып киткәндәй булды, күзләрен әкрен генә ачты. «И-и мескенкәем, сине дә язмыш сыный икән бит», – дия-дия Хәсән карт өенә таба атлады. Бер-ике көн тәрбияләгәч, песи баласы терелде, шаярып, уйный башлады. Шулай итеп ике ялгыз күңел бер-берсен таптылар....

Чираттагы көннәрнең берсендә Хәсән карт радио тыңлап утыра иде. Күңеле тынгысызланып киткән вакытларда кабыза ул радиосын. Бүген хәбәрләр вакытына туры килде. Алып баручы ниндидер мөһим яңалык җиткерә иде: «Өч көн элек Казанның иң зыялы һәм бай кешеләре – Миләүшә һәм Илдар Газиевлар юл һәлакәтенә очрады. Алар икесе дә авыр хәлдә, Казан хастаханәсендә яталар...» Хәсән карт аларның кем икәнен дә белми, тик бу хәбәр аны барыбер тетрәндерде. Бу авариянең сәбәбе ни булгандыр, билгесез: әллә, байларга да кайгы килә, дигәнне исбатлаумы, әллә саулыкны акчага сатып ала алмауны раслаумы, әллә инде кечкенә генә песи баласының рәнҗеше төшүме?..

• Киңәш-табыш

# Компьютерны ничек чистартырга?

**Диләрә БАТРШИНА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Өендә компьютер булмаган кеше юктыр инде хәзерге заманда. Иманым камил, берәү генә дә түгелдер. Беләсегез килсә, компьютер да чисталык ярата һәм аны, тиешле дәрәҗәдә эшләсен өчен, даими рәвештә «юындырып» торырга кирәк.

## Монитор чистартабыз

Компьютер кибетеннән экран чистарту өчен махсус сыеклык һәм йомшак чүпрәк алыгыз. Алар ярдәмендә сез мониторны атнага берничә тапкыр сөртеп тора алачаксыз. Бу эшне башкарганда, су, составында спирт булган сыеклык (мисалга тәрәзә юу өчен) һәм иске тукымалар кулланырга ярамый. Бер дә булмаса, күзлек пыяласын сөртү өчен кулланыла торган чүпрәкне файдаланыгыз. Чистарткан вакытта, яктылык мониторның кырыеннан төшеп торырга тиеш.

## Клавиатура һәм тычкан

Клавиатураны уттан өзеп, өстен аска әйләндерегез һәм, акрын гына суккалап, тузан һәм чүпләреннән арындырыгыз.

Йомшак тукыма алып, аны махсус чистарту сыеклыгы белән чылатыгыз (тукыма дымлы булырга тиеш) һәм клавиатура өстен сөртегез: клавишаны, аның кырыйларын, аякчыкларын, терәткечләрен. Соңыннан клавиатураны чиста чүпрәк белән корытыгыз.

Механик тычканның шарчыгын чистартыгыз (спирт белән чылатылган тукыма ярдәмендә мөмкин). Ә оптик тычканны сүтеп, эчен дә сөртергә кирәк.

Тычкан келәмен сабын белән юып киптерегез. Тычкан белән келәм кимендә өч айга бер тапкыр чистартылырга тиеш.

## Система блогы

Система блогын 6 айга бер тапкыр чистарту кирәк. Барлык чыбыкларны өзеп, арткы ягындагы шөрепләрне сүтегез һәм капкачларын ачыгыз. Синтетик пумала белән тузанын сөртегез, теш щёткасы белән вентиляция тишекләрен, ә теш чистарткыч таякчык белән секция араларын чистартыгыз. Тузанын минималь көчкә куелган тузан суырткыч белән җыегыз. Әгәр дә система блогын беркайчан да сүткәнегез булмаса, ярдәмгә белгечләрне чакыртыгыз.

• Юбилейны каршылап

Уку йортыбызның зур юбилее – 210 еллыгына багышлап, газетабызда, яңа сәхифәләр белән бергә, төрле иҗади бәйгеләр дә игълан итәбез.

**#сиңа, яраткан университетым**

Шушы сүзләрне кертеп, безгә иҗади эшләрегезне юллагыз. Бернинди чикләүләр дә юк: шигырь дә, дүртьюллык та, эссе да язарга мөмкин. Университетыбыз тормышын яктырткан фотосурәтләр дә, үзегез иҗат иткән рәсемнәр дә кабул ителә.

**«Башваткыч»**

Без һәркайсыбызга яхшы таныш «Яңа гасыр» каналында бара торган «Башваткыч» тапшыруы белән берлектә бәйге игълан итәбез. Сездән уку йортыбызга бәйле сораулардан торган кроссвордлар көтеп калабыз. Бәйгедә студентлар, магистрлар, аспирантлар, укытучылар катнаша ала. Иң яхшы кроссворд төзүчене редакциябездән бүләк һәм тапшыруга чакыру көтә. Гомумән, беркем дә бүләксез калмаячак.




Бәйгеләргә эшләрне газетаның электрон почтасына: darelfonyn@mail.ru җибәрергә яки редакиягә кертеп бирергә мөмкин. Эшләр 28 ноябрьгә кадәр кабул ителә.

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.